**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел.+7(84396) 2-58-00 тел./факс +7(84396) 2-58-42, email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.04.2020 **Чирмешән авылы** № 123

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2013 елның 23 сентябрендәге 531 номерлы «Мәктәпкәчә белем бирү буенча гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Премьер-министры А. В. Песошинның 2020 елның 1 апрелендәге 241 номерлы йөкләмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2013 елның 23 сентябрендәге 531 номерлы «Мәктәпкәчә белем бирү буенча гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» карары белән (2014 елның 15 гыйнварындагы 10 номерлы, 2014 елның 17 февралендәге 64 номерлы, 2015 елның 29 октябрендәге 541 номерлы, 2017 елның 17 февралендәге 56 номерлы, 2018 елның 26 гыйнварындагы 40 номерлы, 2019 елның 18 декабрендәге 530 номерлы үзгәрешләр белән) расланган Мәктәпкәчә белем бирү буенча гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә

2 пунктчага түбәндәге эчтәлекле пунктны өстәргә:

«Түләү чоры 2020 елның 30 сентябренә кадәр чыга торган социаль ярдәм чараларын бирүне 2020 елның 1 октябренә кадәр озайтырга, аларны алу өчен гаризаны кабат тапшырмыйча, дәүләт һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә өстәмә компенсация алучы гражданнарга җан башына уртача керем 20,0 мең сумга кадәр булган гаиләләргә.»

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Район Башкарма комитетының
Җитәкчесе И.Н.Шәйдуллин